ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны
бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү турында Татарстан Республикасы мәдәният министры И.Х. Әюпова мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы мәдәният министры И.Х. Әюпова мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү буенча 2024 елның 27 ноябрендәге 2672-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән расланган төп чаралар планын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.2. Каюм Насыйри музеенда – «Татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри яшәгән һәм 1902 елда вафат булган йорт» (Казан шәһәре) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектында ремонт-реставрация эшләрен тизләтү мөмкинлеген карарга.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы Милли музее белән берлектә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Каюм Насыйри музее сайтын һәм музей экспозициясен заманча музей технологияләрен исәпкә алып камилләштерү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары, Татарстан Республикасында мәгариф оешмалары җитәкчеләре белән берлектә педагогларның һәм укучыларның Казан шәһәрендә Каюм Насыйри музеена, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районындагы Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексына һәм Каюм Насыйриның

тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында оештырылган күргәзмә проектларына баруларын оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында уздырыла торган чараларда катнашырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмmәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 254-VII ДС